| МИНИСТЕРСТВО СПОРТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
|---|---|---|
| ____08.07.2024______ | Казан<br>шәһәре | _____335________ |

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2020 елның 15 октябреннән «Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 305 нче номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июленнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февраленнән «Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 175 нче номерлы карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә,

**б о е р а м**:

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2020 елның 15 октябреннән «Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 305 нче боерыгы белән

расланган «Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына» (Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы 2022 елның 22 июненнән 271 нче номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән), аны яңа теркәлә торган редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы спорт министрының беренче урынбасары Х.Х. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
2020 елның 15
октябреннән 305 номерлы
боерыгы белән расланган
(Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
08.07.2024 нан 335
номерлы боерыгы
редакциясендә)

**Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга,физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр:

- тренер, өлкән тренер, адаптив физик тәрбия буенча тренер-укытучы, спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы адаптив физик тәрбия буенча өлкән тренер (алга таба – тренерлар);
- инструктор-методист, өлкән инструктор-методист, адаптив физик тәрбия буенча инструктор-методист, адаптив физик тәрбия буенча өлкән инструктор-методист (алга таба – физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләр);

Дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап, гариза бирүченең Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамәгә нигезләнгән вәкаләтләре нигезендә эш итүче вәкиле (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле) мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә профильләштерү (хезмәт күрсәтүче орган үткәрә торган анкеталау нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү) үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы.

Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә квалификация категорияләре бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы.

2.2.1 Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы орган – Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык).

2.2.2. Дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) күрсәтелми.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

Министрлыкның «Татарстан Республикасында тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә беренче һәм югары квалификация категориясен бирү турында» боерыгы белән рәсмиләштерелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар (1 нче кушымта) , яисә квалификация категориясен бирүдән баш тарту турында карар (2 нче кушымта).

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле затның фамилиясе, инициаллары;

электрон имза турында белешмәләр (боерыкка электрон имза белән кул куйганда).

2.3.3. Квалификация категориясен бирүдән баш тарту турындагы карар реквизитлары:

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

гариза бирүченең (гариза бирүче вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), элемтә өчен белешмәләре;

карар номеры һәм датасы;

баш тарту нигезләре;

карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле затның фамилиясе, инициаллары;

электрон имза турында белешмәләр (боерыкка электрон имза белән кул куйганда).

2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып реестр язмасы тормый.

2.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе нинди дә булса мәгълүмат системасында теркәлми.

2.3.6. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә ала:

- шәхсән кәгазьдә;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) төбәк порталы (алга таба – Республика порталы) аша  (www.uslugi.tatar.ru);

- почта элемтәсе аша;

- электрон почта адресы буенча.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты.

2.4.1. Дәүләт хезмәте гариза бирүче почта элемтәсе, Министрлыкның электрон почтасы аша яки шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта Министрлыкта гариза һәм документлар теркәлгән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнелә торган 55 көн вакыт эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Гариза бирүче гариза бирүченең Республика порталындагы шәхси кабинеты (алга таба – шәхси кабинет) аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте Республика порталындагы шәхси кабинетында чагылыш тапкан эшләр номенклатурасы нигезендә гаризага номер бирелгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 55 көн эчендә күрсәтелә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы сайтында, Республика порталында, Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең бердәм порталында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Тренерларга квалификация категориясен бирү өчен түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

1) Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2020 елның 19 мартыннан «Тренерларның квалификация категорияләрен бирү тәртибен һәм тренерларның квалификация категорияләрен бирүгә квалификация таләпләрен раслау турында» 224 нче номерлы боерыгы белән расланган Тренерларның квалификация категорияләрен бирү тәртибенә (алга таба – 2020 елның 19 мартыннан 224 номерлы Тәртип) кушымтада китерелгән форма буенча квалификация категориясе бирү турында гариза;

2) Россия Федерациясе гражданы паспортының икенче һәм өченче битләренең күчермәләре, шулай ук мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны турында белешмәләре булган битләрнең күчермәләре;

3) квалификация категориясе бирелүне раслаучы документ күчермәсе (булганда);

4) спортчының яки спорт әзерлеге узучы затның физик культура-спорт оешмасына яки спорт әзерлеге өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы оешмага керүен раслый торган җитәкче имзасы һәм оешма мөһере белән (булган очракта) расланган документ күчермәсе;

5) спортчыны тренерның тренировка төркеменә кертү турында яки спорт әзерлеге өстәмә белем бирү программасы буенча укуга кабул итү турында боерыктан оешма җитәкчесе имзасы һәм мөһере белән (булган очракта) расланган өземтә;

6) баш хөкемдарлар коллегиясе рәисе, рәсми спорт чарасының баш хөкемдары имзалаган рәсми спорт чарасы беркетмәсенең күчермәсе яисә беркетмәсеннән өземтә;

7) спорт әзерлеге узучы затка яки спортчыга спорт исеме һәм (яки) спорт разряды бирү турында боерыкның оешма җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән расланган күчермәсе;

8) спорт әзерлеге узучы затны спорт әзерлегенең киләсе этабына күчерү турында оешма җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән расланган боерыктан өземтә;

9) спорт әзерлеге узучы затның яки спортчының Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларына кандидатлар исемлегенә кертелүен раслый торган күрсәтмә актының күчермәсе;

10) гариза бирүченең семинарларда, конференцияләрдә, ачык дәресләрдә, мастер-классларда һәм башка фәнни-гамәли чараларда катнашуы турында күрсәтелгән чараларны оештыручылар тарафыннан бирелгән документның күчермәсе (булган очракта);

11) гариза бирүченең һөнәри эшчәнлеге чорында мактаулы спорт исемнәре һәм (яисә) ведомство бүләкләре, кызыксындыру чаралары бирелүне раслый торган документның күчермәсе (булган очракта);

12) методик эшкәртмәләр (публикацияләр) күчермәләре (булган очракта).

2.6.2. Физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә квалификация категориясен бирү өчен түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

1) Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2019 елның 19 декабреннән «Физик культура һәм спорт өлкәсендә башка белгечләрнең квалификация категорияләрен бирү тәртибен һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә башкабелгечләрнең квалификация категорияләрен бирүгә квалификация таләпләрен раслау турында» 1076 нчы номерлы боерыгы белән расланган Тренерларның квалификация категорияләрен бирү тәртибенә (алга таба – 2019 елның 19 декабреннән 1076 нчы номерлы Тәртип) кушымтада китерелгән форма буенча квалификация категориясе бирү турында гариза;

2) Россия Федерациясе гражданы паспортының икенче һәм өченче битләренең күчермәләре, шулай ук гариза бирүченең яшәү урыны турында белешмәләре булган битләрнең күчермәләре;

3) гариза бирүченең семинарларда, конференцияләрдә, мастер-классларда һәм башка фәнни-гамәли чараларда катнашуы турында күрсәтелгән чараларны оештыручылар тарафыннан бирелгән документның күчермәсе (булган очракта);

4) гариза бирүченең һөнәри эшчәнлегенең барлык чорында мактаулы спорт исемнәре һәм (яки) ведомство бүләкләре, кызыксындыру чаралары бирелүне раслый торган документ күчермәсе (булган очракта);

5) методик эшкәртмәләр (публикацияләр) күчермәләре (булган очракта).

2.6.3. Гариза һәм теркәп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) Республика порталы аша электрон формада;

2) Министрлыкка шәхсән яки гариза бирүче вәкаләтле зат тарафыннан;
3) почта элемтәсе аша кәгазьдә.
4) электрон почта аша.

Гариза һәм бирелә торган документлар почта элемтәсе аша юлланганда, алар законнар белән билгеләнгән тәртиптә раслана.

2.6.4. Гариза һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүчеләр гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада Идентификация һәм аутентификацияләүнең бердәм системасында (алга таба – ИАБС) теркәү (аутентификацияләү) процедурасын узарга, шулай ук исәпкә алынуның стандарттан да түбәнрәк булмаган дәрәҗәгә кадәр расларга кирәк.

Гаризаны Республика порталы аша җибәргәндә, гариза биргән көнне гариза бирүче шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелгәнлеген раслый торган хәбәрнамә ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелә.

Ышанычнамә – электрон документ (документның электрон образы) мондый документларны төзү һәм имзалауга вәкаләтле затларның, шул исәптән нотариуслар тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле имза белән раслана.

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (электрон документлар образлары), шул исәптән ышанычнамәләр pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларында 50 Мбайттан да зуррак булмаган файллар рәвешендә җибәрелә.

Бирелә торган электрон документларның (документларның электрон образлары) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш.

Гариза бирүче Республика порталы аша гариза биргәндә, әлеге Регламентның 2.6.1 һәм 2.6.2. пунктларында күрсәтелгән документларның электрон образларын яисә документларны 2011 елның 6 апреленнән «Электрон имза турында» 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре буенча мондый документларны төзү һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән расланган электрон формада бирә.

2.6.5. Ведомствоара хезмәттәшлек итү кысаларында:

хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр – Россия Федерациясенең пенсия һәм социаль иминият фондыннан. алына

2.6.6. Гариза бирүче ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән алына торган документларны мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы.

Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлар текстында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган бозу һәм төзәтүләр булу;

2) документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларда булган мәгълүмат һәм белешмәләрне тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми торган кимчелекләр булу;

3) тапшырылган документлар дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать иткән вакытка үз көчләрен югалткан булуы(күрсәтелгән зат тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ);

4) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны билгеләнгән таләпләрне бозып электрон формада бирү;

5) гариза формасындагы мәҗбүри кырларны, шул исәптән Республика порталындагы интерактив формадагы гаризаны дөрес тутырмау (дөрес түгел, тулы түгел яисә дөрес тутырылмаган);

6) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаның 2020 елның 19 мартыннан 224 номерлы Тәртиптә яки 2019 елның 19 декабреннән 1076 номерлы Тәртиптә билгеләнгәнгән таләпләргә туры килмәве;

7) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы булмаган комплектын тапшыру;

8) хезмәт күрсәтү турында гаризаны дәүләт хезмәте күрсәтү вәкаләтләренә керми торган дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшыру;

9) 2011 елның 6 апреленнән «Электрон имза турында» 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсендә билгеләнгән (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның гамәлдә булуын тану шартларын үтәмәү – Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә;

10) беренче яисә югары квалификация категориясен бирү турында гаризаны икенче квалификация категориясен биргәннән соң бер елдан да иртәрәк бирү.

2.7.2. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар Республика порталында бастырылган дәүләт хезмәте күрсәтү вакытлары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.7.4. Документларны кабул итүдән баш тарткан очракта гариза бирүчегә әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы нигезендә тренерга, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белгечкә квалификация категориясен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар җибәрелә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып гариза бирүченең һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләренең Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2020 елның 19 мартыннан «Тренерларның квалификация категорияләрен бирү тәртибен һәм тренерларның квалификация категорияләрен бирүгә квалификация таләпләрен раслау турында» 224 номерлы боерыгы яисә Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2019 елның 19 декабреннән «Физик культура һәм спорт өлкәсендә башка белгечләрнең квалификация категорияләрен бирү тәртибен һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә башка белгечләрнең квалификация категорияләрен бирүгә квалификация таләпләрен раслау турында» 1076 номерлы боерыгы белән билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килмәве тора.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

2.9.1. Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүенең максималь вакыты.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.10.2. Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында соравын теркәү вакыты.

2.11.1. Гаризаны Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Республика порталында шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гариза җибәрелүен раслаучы теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән хәбәрнамә ала.

2.11.2. Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, вәкаләтле зат тарафыннан гариза биргән көнне, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан теркәү номеры, гариза бирү датасы һәм тапшырылган документлар исемлеге белән расписка бирелә.

2.11.3. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килгән көндә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бинада башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматлары гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

2.12.2. Инвалидларның (кресло-коляска һәм озатып йөрүче этләрне да кертеп) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуын оештыру максатларында аларга түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылуга ия булган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

2) Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, шул исәптән кресло-коляска кулланып, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге;

3) инвалидларның бинага, бүлмәләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә, тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне тиешенчә урнаштыру;

4) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билге һәм Брайль рельеф-нокталы шрифты белән башкарылган башка текст һәм график мәгълүматны кабатлау;

5) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә белән рөхсәт бирү;

6) махсус укытуны раслый торган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июненнән «Озатып йөри торган этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча бирелә торган документы булганда, озатып йөрүче этне кертү;

7) Министрлык хезмәткәрләренең инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә комачаулый торган киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтүе.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яки капиталь ремонт, реконструкцияләү, модернизацияләү үткән объектларга карата кулланыла.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре.

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

- документларны кабул итү, бирү алып барыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашкан булуы;

- белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;

- мәгълүмати стендларда, Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

- гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге;

- Министрлык хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтү алуга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) документлар кабул итү һәм карау вакытларын саклау;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытын саклау;

3) Министрлык хезмәткәрләренең Регламентны бозуларына нигезләнгән шикаятьләр булмау;

4) гаризпа бирүче һәм вазыйфаи затның үзара тәэсир итешүе саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

- дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүченең Министрлык хезмәткәрләре белән үзара хезмәттәшлеге барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

- Министрлыкта дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ нөсхәсе рәвешендә кәгазьдә алу кирәк булган очракта – бер тапкыр.

Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлегенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Гариза бирүче, Республика порталын кулланып, күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә хокуклы.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Республика порталында шәхси кабинетында, Министрлыкта алырга мөмкин.

2.13.4. Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы сорау (запрос) составында күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы;

дәүләт хезмәте турында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирү турында.

2.14.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәткәндә гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Республика порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

2) Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган башка документларны, шул исәптән электрон рәвешләре 2010 елның 27 июненнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 16 маддәсендәге 1 өлешенең $7^2$ пункты белән билгеләнгән документлар һәм мәгълүмат элегрәк расланган документлар һәм мәгълүматны бирергә;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формада бирелгән гаризаларның үтәлү барышы турында белешмәләр алырга;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

6) Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан башкарылган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларына) судка кадәр шикаять

бирү процессын тәэмин итүче Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, башка нинди дә булса формада гаризаны өстәмә бирү зарурлыгыннан тыш, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән башкарыла.

2.14.3. Гариза тутырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документларны күчереп алу һәм саклау мөмкинлеге;

2) берничә гариза бирүченең уртак гаризасын юллауны күз алдында тоткан хезмәтләрне сорап мөрәҗәгать иткәндә, берничә гариза бирүче гаризасының бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

3) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

4) кулланучының теләге буенча теләсә кайсы вакытта, шул исәптән гаризаның электрон формасына зурлыкларны кабат кертү өчен хаталар килеп чыкканда һәм кире кайтканда, гаризаның электрон формасына элегрәк кертелгән зурлыкларны саклау;

5) Республика порталында урнаштырылган мәгълүматлардан файдаланып, гариза бирүченең мәгълүматларын кертү алдыннан гаризаның электрон формасы кырларын тутыру;

6) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына кире кайту мөмкинлеге;

7) гариза бирүченең элек бирелгән гаризаларына бер елдан да ким булмаган вакыт эчендә, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларына – кимендә 3 ай эчендә керү мөмкинлеге.

2.14.4. Гариза бирүчедән, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакытлыча интервал дәвамлылыгын исәпләү өчен кирәк булган мәгълүматлардан тыш, башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакытлары

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген сурәтләү

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, шул исәптән гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү буенча ярдәм күрсәтү;

2) гариза бирүче тәкъдим иткән документлар комплектын кабул итү һәм карау;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар төзү һәм җибәрү;

4) кергән документларны карау һәм документларны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының Тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы боерыгы белән оештырылган комиссиясенә (алга таба – Комиссия) тапшыру;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (юллау);

6) техник хатаны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик хаталар) төзәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү.

3.2.1 Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате административ процедураны башкаруны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

Гариза бирүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә, административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып спорт резервы әзерлеге секторы хезмәткәре (алга таба – Сектор хезмәткәре) тора.

3.2.2. Гариза бирүче Министрлыкка шәхсән, телефон аша һәм (яки) почта аша (шул исәптән электрон) мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибе һәм вакытлары, шул исәптән тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка мәсьәләләр буенча Республика порталында, Министрлык сайтында консультация алырга хокуклы.

Сектор хезмәткәре гариза бирүчегә, шул исәптән гариза формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультация бирә. Кирәк булганда, Сектор хезмәткәре гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә, ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.3. Гариза бирүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче гаризаны шәхсән, вәкиле аша, почта (шул исәптән электрон) аша һәм Республика порталындагы шәхси кабинеты аша бирә ала.

3.3.1.1. Гариза бирүче Республика порталы аша электрон формада гариза бирү өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

- авторизацияләү үтә;

- электрон гариза формасын ача;

- дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

- электрон гариза формасына электрон формада документларны яки документларның электрон үрнәкләрен беркетә;

- электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле билге куя);

- хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле билге куя);

- тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

- электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзалана;

- электрон гариза җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Гариза формалаштырганда гариза бирүчегә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле Регламентның 2.6.1, 2.6.2 пунктларында күрсәтелгән башка документларны күчереп алу һәм саклау мөмкинлеге;

2) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

3) кулланучының теләге буенча теләсә кайсы вакытта, шул исәптән гаризаның электрон формасына зурлыкларны кабат кертү өчен хаталар килеп чыкканда һәм кире кайтканда, гаризаның электрон формасына элегрәк кертелгән зурлыкларны саклау;

4) ИАБС да урнаштырылган белешмәләрдән файдаланып, һәм ИАБС да булмаган белешмәләр өлешендә Республика порталында урнаштырылган мәгълүматлардан файдаланып, гариза бирүченең мәгълүматларын кертү алдыннан гаризаның электрон формасы кырларын тутыру;

5) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына кире кайту мөмкинлеге;

6) гариза бирүченең элек бирелгән гаризаларына бер елдан да ким булмаган вакыт эчендә, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларына – кимендә 3 ай эчендә керү мөмкинлеге.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар гаризаны теркәү көнендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып Министрлыкка электрон хезмәттәшлек системасы аша җибәрелгән электрон эш тора.

3.3.2. Министрлыкның документлар комплектын каравы.

3.3.2.1. Административ процедураны башкаруны башлап җибәрү өчен нигез булып гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар керү тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып Сектор хезмәткәре тора:

Сектор хезмәткәре гариза бирүче Министрлыкка гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта:

- мөрәҗәгать итүнең предметын билгели;

- гариза бирүченең шәхесен ачыклый;

- документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

- документларның Регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен, бирелгән документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда чистартулар, өстәп язулар, астына сызылган сүзләр һәм башка әйтелмәгән төзәтүләр булмауны) тикшерә;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында гаризаның электрон формасын тутыра;

- Регламентның 2.6.1 яки 2.6.2 пунктларында күрсәтелгән документларны кәгазьдә тапшырган очракта, тапшырылган документларны сканерлый;

- гаризаны бастыра;

- тикшерү һәм имзалау өчен гариза бирүчегә бирә;

- кул куйганнан соң имзаланган гаризаны сканерлый;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасына электрон формада тәкъдим ителгән документларны яки сканерланган документларның электрон образларын йөкли, электрон эш формалаштыра.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Сектор хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итү өчен киртәләр булу турында телдән хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кире кайтара. Гариза бирүченең соравы буенча шәхсән мөрәҗәгать иткәндә документларны кабул итүдән язмача баш тарту бирелә.

Гариза һәм документларны почта (шул исәптән электрон) аша алганда – гариза һәм документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, документларны кире кайтара (3 нче кушымта).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозуга бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрдә тапшырылмаган документларның (мәгълүмат, белешмәләрнең) атамалары, дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы мәгълүмат булуы, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән икәнлеге турында белешмәләр булырга тиеш)) электрон документ әйләнеше системасы ярдәмендә килештерү өчен вәкаләтле вазыйфаи затка җибәрелә.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның гамәлдә булу шартларның үтәлмәве ачыкланган очракта, баш тарту турында карар проектында аны кабул итү өчен нигез булып торган 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсе пунктлары булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан имзалана.

Гариза кире кайтарылган очракта, аны биргән гариза бирүче, гариза кире кайтарылган көннән алып биш эш көне эчендә, туры килмәүләрне бетерә һәм аны карау өчен Министрлыкка кабат җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта Сектор хезмәткәре:

- эшләр номенклатурасы буенча гаризага номер куя.

- гаризада күрсәтелгән ысул белән гариза бирүчегә гаризаның керү теркәү номеры, гаризаны алу датасы, тапшырылган документларның файллар атамалары исемлеге, дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу датасы язылган гариза керү турында хәбәрнамә җибәрә (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә бирә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедураларны үтәү, техник мөмкинлекләр булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар кирәкле документлар белән гариза кергән көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: теркәлгән гариза яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Запрос җибәрү өчен нигез булып гариза бирүченең теркәлгән гаризасы тора.

3.4.2. Ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат Регламентның 2.6.5 пунктында каралган документлар һәм белешмәләр бирү турында запрослар (шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдаланып) әзерли һәм җибәрә.

3.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле сорала торган документлар исемлеге:

хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр. Запрос Россия Федерациясенең Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә.

Ведомствоара мәгълүмат запросы күрсәтелгән органга гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатыннан җибәрелә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәп бирелгән документларны теркәү көнендә башкарыла.

3.4.4. Регламентның 2.6.5 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яисә алардагы белешмәләр) ведомствоара запрослар буенча әлеге документлар үз карамагында электрон формада булган органнар тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 23 июненнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек, шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыру кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер

актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 963 нче номерлы карары нигезендә тиешле ведомствоара запрос җибәрелгән вакыттан алып 48 сәгатьтән дә соңга калмыйча бирелә.

3.4.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазьдә алып барылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон рәвештә булмау сәбәпле, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон рәвештә гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда;

2) ведомствоара запрос җибәргәндә, документларның төп нөсхәләрен кәгазьдә тапшыру кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазьдә гамәлгә ашырылса, Регламентның 2.6.5 пунктчасында каралган документлар (аларның күчермәләре яисә алардагы белешмәләр) шул документлар булган органнар тарафыннан бирелә.

Ведомствоара запросларга җавап әзерләү һәм җибәрү вакыты 210-ФЗ номерлы Федераль законның $7^2$ маддәсендәге 3 өлеше нигезендә ведомствоара запрос кергән көннән алып биш эш көненнән артмаска тиеш.

Процедураның нәтиҗәсе булып соралган документларны (аларның күчермәләрен яисә алардагы белешмәләрне) алу яисә ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән сорала торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә тора.

Белешмәләрдән файдалануның максатлары булып гариза бирүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм гариза бирүченең хокукларын бозуны булдырмаслык карарлар кабул итү тора.

3.5. Кергән документларны карау һәм документларны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының Тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча комиссиясенә тапшыру.

Квалификация категорияләре бирү өчен кирәкле документлар белән гаризаны карау Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының Тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан Министрлыкның 2020 елның 7 декабреннән «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының Тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча комиссиясе турында Нигезләмәне, шулай ук комиссия составын раслау турында» 384 нче номерлы боерыгы белән раслана торган Комиссия турындагы Нигезләмә нигезендә үткәрелә.

3.5.1. Сектор хезмәткәре Комиссия каравы өчен гариза бирүчеләр исемлеген төзи һәм аны Регламентның 2.6.1, 2.6.2 пунктларында билгеләнгән документлар белән бергә Комиссиягә җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар белән бергә Комиссиягә җибәрелгән төзелгән исемлек.

3.5.2. Комиссия утырышын оештыру өчен Сектор хезмәткәре Комиссия әгъзаларына чакыру хаты җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: комиссия әгъзаларына чакыру хатлары.

3.5.3. Утырыш беркетмәсе нигезендә Комиссия эксперт төркеме тарафыннан гариза бирүчеләрнең һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләренә бәйсез эксперт бәяләве уздыру турында карар кабул итә.

3.5.4. Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә Бүлек хезмәткәре «Квалификация таләпләренә туры килүгә һөнәри эшчәнлек нәтиҗәләренә эксперт бәяләве уздыру турында» Министрлык боерыгы проектын төзи һәм килештерүгә боерык проектын министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: килештерүгә министрның беренче урынбасарына юлланган боерык проекты.

3.5.5. Министрның беренче урынбасары боерык проектын карый, килештерү турында карар кабул итә һәм министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) җибәрелгән боерык проекты.

3.5.6. Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) эксперт бәяләве уздыру турындагы боерыкка кул кую турында карар кабул итә.

Процедура нәтиҗәсе: имзаланган боерык.

3.5.7. Регламентның 3.5.1-3.5.6 пунктларында билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган көннән алып биш эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

3.5.8. Эксперт төркеме гариза бирүчеләрнең һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләренә бәйсез эксперт бәяләве уздыра. Эксперт төркеме карары акт белән рәсмиләштерелә. Акт Сектор хезмәткәренә тапшырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедура алдагы процедура тәмамланган көннән алып 38 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Административ процедура нәтиҗәсе: бәйсез эксперт бәяләве үткәрү турында акт.

3.5.9. Сектор хезмәткәре, эксперт төркеменнән бәйсез эксперт бәяләве уздыру турында актлар алганнан соң, Комиссиянең йомгаклау утырышын оештыру буенча эш алып бара.

3.5.10. Гариза бирүчегә квалификация категориясен бирү/бирүдән баш тарту турында Комиссия карары Комиссиянең йомгаклау утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Процедура нәтиҗәсе: Комиссиянең йомгаклау утырышы беркетмәсе.

3.5.11. Регламентның 3.5.9-3.5.10 пунктларында билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган көннән алып биш эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Административ процедураны башкаруны башлау өчен нигез булып Комиссия йомгаклау утырышы беркетмәсе тора.

Комиссиянең йомгаклау утырышы беркетмәсе нигезендә Министрлык гариза бирүчегә квалификация категориясе бирү/бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

3.6.2 Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат булып Сектор хезмәткәре тора.

3.6.3 Сектор хезмәткәре Министрлыкның «Татарстан Республикасында тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә беренче һәм югары квалификация категориясе бирү турында» боерыгы проектын яисә квалификация категориясен бирүдән баш тарту турында хезмәт язуы проектын төзи һәм килештерүгә министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына килештерүгә җибәрелгән боерык проекты яисә квалификация категориясен бирүдән баш тарту турында хезмәт язуы проекты.

3.6.4. Министрның беренче урынбасары Министрлыкның «Татарстан Республикасында тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә беренче һәм югары квалификация категориясе бирү турында» боерыгы проектын яисә квалификация категориясен бирүдән баш тарту турында хезмәт язуы проектын килештерү турында карар кабул итә һәм раслау өчен министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) кул куюга җибәрелгән боерык проекты яисә хезмәт язуы проекты.

3.6.5. Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) «Татарстан Республикасында тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә беренче һәм югары квалификация категориясе бирү турында» боерыкка кул кую турында карар кабул итә яисә килештерелгән хезмәт язмасына тиешле резолюция сала һәм Сектор хезмәткәренә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкның имзаланган боерыгы яисә министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) резолюциясе белән хезмәт язуы

3.6.6. Сектор хезмәткәре министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) резолюциясе нигезендә квалификация категориясен бирүдән баш тарту турында карар проектын әзерли, Регламентның 3.6.3-3.6.5 пунктларында билгеләнә торган процедураларны гамәлгә ашыра.

Процедура нәтиҗәсе: квалификация категориясен бирүдән баш тарту турында карар.

3.6.7. Регламентның 3.6.3-3.6.6 пунктларында билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган көннән алып биш эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

3.6.8. Сектор хезмәткәре:

- гаризада күрсәтелгән ысул белән гариза бирүчегә (гариза бирүче вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм Министрлыкта дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып бару подсистемасына дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында белешмәләрне теркәү һәм кертүне, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында «Татарстан Республикасында

тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә беренче һәм югары квалификация категориясе бирү турында» боерык урнаштыруны тәэмин итә.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлекләр булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып гариза бирүчегә (гариза бирүченең вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү, Министрлыкның рәсми сайтында «Татарстан Республикасында тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә беренче һәм югары квалификация категориясе бирү турында» боерык урнаштыру тора.

3.7 Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.7.1 Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен сорап Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүченең шәхси кабинетына дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган документның электрон формасы автомат рәвештә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне раслый торган документка имза салынган көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: гариза бирүчегә Республика порталы ярдәмендә дәүләт хезмәте күрсәтүне раслый торган документны җибәрү (тапшыру).

3.7.2 Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу өчен гариза бирүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә, Сектор хезмәткәре гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирә (җибәрә). Гариза бирүче таләбе буенча аңа Министрлыкның «Татарстан Республикасында тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә беренче һәм югары квалификация категориясе бирү турында» боерыгы яки квалификация категориясе бирүдән баш тарту турында карар нөсхәсе гариза бирүче адресына электрон почта аша тапшырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар чират тәртибендә, гариза бирүче килгән көнне Министрлыкның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре нигезендә – шәхсән, дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) кул куйган көнне – почта элемтәсе, электрон почта аша гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:
гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү), дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү фактын дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәү.

3.8. Техник хатаны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.8.1. Техник хатаны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хатаны) (алга таба – техник хата) төзәтү.

3.8.2 Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка түбәндәгеләрне юллый:

- техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 4 нче кушымта);

- дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә бирелгән техник хата булган документ;

- юридик көчкә ия, техник хата булуын раслаучы документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (гариза бирүче вәкиле) тарафыннан түбәндәге ысуллар белән: Министрлыкка шәхсән, почта (шул исәптән электрон почта) аша яисә Республика порталы аша бирелә.

3.8.3. Сектор хезмәткәре техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм теркәп бирелгән документлар белән гаризаны терки.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар гаризаны теркәү датасыннан алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып кабул ителгән һәм теркәлгән гариза тора.

3.8.4. Сектор хезмәткәре документларны карый һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында Регламентта каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны, гариза бирүчедән (вәкилдән) техник хата булган документның оригиналын алып, шәхсән имза куйдырып гариза бирүчегә (вәкилгә) тапшыра, яисә гариза бирүчегә почта аша (электрон почта аша), техник хата булган документның төп нөсхәсен Министрлыкка тапшырганда, документ алу мөмкинлеге турында хат юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуталар техник хатаны ачыклаганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ тора.

**4. Административ регламент үтәлешен тикшерү формалары.**

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклау һәм юкка чыгаруны, шикаятьләр карауны, тикшерүләр уздыру, гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләренә җавап әзерләүне һәм карарлар кабул итү, Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәлсезлекләренә) карарлар әзерләүне ала.

Административ процедуралар үтәлешен саклауны тикшерү формалары булып түбәндәгеләр тора:

эш башкаруны алып бару;

документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүе;

документларны кабул итү вакытларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында нәтиҗәләрне бирү вакытларын һәм тәртибен үтәү.

Тикшерүләр үткәрүнең кабатланып торуы планлы (эш планы нигезендә уздырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең аерым мөрәҗәгате буенча) характерда була.

Әлеге Регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән административ процедуралар үтәлешен тикшерүне тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча белешмә (справка) бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеген саклауны агымдагы тикшерү министрның беренче урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозган очраклар ачыкланган очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләр (шикаятьләр) карауның судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат бирү юлы белән тормышка ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәлсезлекләренә) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләрнең Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә Министрлыкның дәүләт гражданлык хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәлсезлегенә) карата судка кадәр Министрлыкка дәгъва бирү хокукы бар.

Министрның карарлары, дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле гамәлләренә (гамәлсезлегенә) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын (запрос) теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытын бозу;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында бирү яки гамәлләр кылу каралмаган документлар яки мәгълүматлар бирүне яисә гамәлләр кылуны таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр кире кагу өчен сәбәпләр федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү кертүне таләп итү;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар яисә хәреф хаталарын төзәтүдән баш тартуы яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуы;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) әгәр туктатып тору өчен сәбәпләр федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 маддәсе 1 өлеше 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул иткәндә беренчел кире кагу вакытында аларның булмавы яисә дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат таләп итү.

5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты http://minsport.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы (http://uslugi.tatarstan.ru/) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчедән шәхси кабул итү вакытында кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаять кергәннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгәннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органга, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи затына гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән язудагы һәм басмадагы хаталарны төзәтүдән баш тартуга карата шикаять белдергән очракта яисә мондый төр төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуга шикаять язган очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне дәвамында.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарлары яисә гамәлләренә (гамәлсезлегенә) карата шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яки дәүләт гражданлык хезмәткәренең (исеме);

2) гариза бирүче – физик затның исеме, фамилиясе, атасының исеме (булган очракта), тору урыны турында белешмә, гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамәлсезлекләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамәлсезлеге) белән килешмәгән дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан үзенең дәлилләрен раслый торган документлар (булганда) я аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буларак түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда язуда һәм басмада җибәрелгән хаталарны төзәтүе, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән алу каралмаган акчалата чараларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә, шулай ук башка формаларда;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача яисә гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән җавап юллана.

5.6. Шикаятьне канәгатьләндерерлек дип таныган очракта, гариза бирүчегә адресланган җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта ачыкланган бозуларны кичекмәстән юкка чыгару максатында Министрлык тарафыннан тормышка ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлык өчен гафу үтенелә һәм алга таба дәүләт хезмәтен алу максатында гариза бирүчегә башкарырга кирәк булган эш-гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерерлек түгел дип тапкан очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләрен күрсәтеп нигезләнгән аңлатма, шулай ук әлеге карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат булган барлык материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

Татарстан Республикасы
территориясендә тренерларга, физик
культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче
белгечләргә квалификация
категорияләре бирү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына
1 нче кушымта

Боерык проекты

Татарстан Республикасы
территориясендә тренерларга, физик
культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче
белгечләргә квалификация категорияләре
бирү турында

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2020 елның 19 мартыннан 224 номерлы боерыгы белән расланган Тренерларның квалификация категорияләрен бирү тәртибенең 25 пункты, Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2019 елның 19 декабреннән 1076 номерлы боерыгы белән расланган Физик культура һәм спорт өлкәсендә башка белгечләрнең квалификация категорияләрен бирү тәртибенең 23 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы спорт министрлыгының Тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә квалификация категорияләре бирү комиссиясе (алга таба – Комиссия) _ _ _ _ _ _ _ _ 20_ _ _ елдан карары нигезендә Комиссиягә кергән тренерлар, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләрнең гаризаларын карау йомгаклары буенча,

**б о е р а м:**

1. Татарстан Республикасы тренерларына, физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләренә кушымта нигезендә беренче, югары квалификация категориясен билгеләргә.
2. Югарыда күрсәтелгән тренерлар һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләр эшчәнлек алып бара торган оешмалар җитәкчеләренә, комиссия утырышында уңай карар кабул ителгән көннән алып, билгеләнгән квалификация категорияләрен (тиешенчә беренче яисә югары) исәпкә алып, хезмәт өчен түләүне 20 _ _ _ _ _ елның _ __ _ _ _ _ елыннан алып башкаруны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы спорт министрының беренче урынбасары_________________йөкләргә.
(Фамилия, инициаллар)

Министр ______________________
(аның вазыйфаларын башкаручы зат)
(Фамилия, инициаллар)

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгы
боерыгына кушымта
20__елның. ___________ №
__________

| № | Муниципаль берәмлек атамасы | Спорт учреждениесе атамасы | Гариза бирүченеңФИАи (атасының исеме - булганда) | Вазыйфасы | Бирелгән категория |
|---|---|---|---|---|---|

Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Форма

Кемгә: ___________________________
___________________________________
Контакт мәгълүматлары:
_____________
___________________________________
Вәкил: __________________
___________________________________
Вәкилнең контакт мәгълүматлары:
___________________________________

Тренерга, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечкә квалификация категориясен бирү/бирүдән баш тарту турында
________________ дан_______________ № лы
КАРАР

Сезнең ________________ _________ номерлы гаризагызны һәм аңа теркәп бирелгән документларны караганнан соң, Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2019 елның 19 декабреннән 1076 номерлы боерыгы һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2020 елның 19 мартыннан 224 номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан тренерга, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечкә квалификация категориясен бирү/бирүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

Баш тарту сәбәбе: _________________________________________.

| |
|---|
| Электрон имза турында белешмәләр |

Министр
(аның вазыйфаларын башкаручы зат) _______________________
(Фамилия, инициаллар)

Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Форма

Кемгә _________________________
__________________________________
Контакт мәгълүматлары: ____________
__________________________________
Вәкил: ________________
__________________________________
Вәкилнең контакт мәгълүматлары:
__________________________________

Тренерга, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечкә квалификация категориясен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында

________________ ________________№ лы

КАРАР

Сезнең ________________ ________ номерлы гаризагызны һәм аңа теркәп бирелгән документларны караганнан соң һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2019 елның 19 декабреннән 1076 номерлы боерыгы һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2020 елның 19 мартыннан 224 номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртипкә нигезләп, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан түбәндәге сәбәпләр аркасында тренерга, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә эшләүче белгечкә квалификация категориясен бирү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту турында карар түбәндәге сәбәпләр буенча кабул ителде:

1. ________________________________________________________________
2. ________________________________________________________________

Сез, күрсәтелгән җитешсезлекләрне юкка чыгарганнан соң, хезмәт күрсәтү турында гариза белән Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге баш тартуга Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына судка кадәр тәртиптә шикаять юллау юлы белән, шулай ук суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

| Электрон имза турында мәгълүматлар |
|---|

Вазыйфаи зат ________________________

(Фамилия, инициаллары)

Татарстан Республикасы
территориясендә тренерларга, физик
культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче
белгечләргә квалификация
категорияләре бирү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына
4нче кушымта

Форма

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм

_____________________________________________________________________
(хезмәт атамасы)

Язылган:_____________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:___________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, карарны җибәрүегезне сорыйм:

________ e-mail адресына электрон документ юллау юлы белән;

кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адрес буенча:_____________________________________________________________________.

Минем шәхесемә һәм мин тәкъдим иткән затка караган гаризага кертелгән, шулай ук мин керткән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәп бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытта бу документлар гамәлдә һәм дөрес белешмәләрне үз эченә ала.

______________ ________________ (_____________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.и.(атасының исеме – булган очракта))

Татарстан Республикасы
территориясендә тренерларга, физик
культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче
белгечләргә квалификация категорияләре
бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
кушымта (белешмә)

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен тикшерүдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 8 (843) 222-81-01(02) | Vladimir.Leonov@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары | 8 (843) 222-81-03 | Halil.Shayhutdinov@tatar.ru |
| Спорт резервы әзерлеге секторы мөдире | 8 (843) 222-81-72 | Aydar.Kadyrov@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру мәсьәләләре бүлеге башлыгы | +7 (843) 264-75-92 | Raushan.Zaripov@tatar.ru |